ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «08» июленнән № 281

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабендәге № 323 карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабендәге № 323 карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пункттагы «Программаны финанс белән тәэмин итү» 1 пунктчасында 2021 елга «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт

мәктәбе» МБУнең матди – техник базасын ныгыту» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь кирәк-яраклары сатып алу өчен» сүзләренә алыштырырга.

2) «Программаны финанс белән тәэмин итү» 6 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә: «Спорт төрләре буенча спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү, әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә хезмәтләр өчен 2021 елга финанс чыгымнары (республика бюджеты) 140,70 мең сум».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов